КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 8 сентябрь г.Казань № 677

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче; 2018 ел, 24 август, 697 нче; 2019 ел, 19 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 15 май, 394 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1177 нче; 2020 ел, 6 март, 179 нчы; 2020 ел, 21 сентябрь, 849 нчы; 2021 ел, 13 апрель, 244 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 956 нчы; 2022 ел, 25 март, 271 нче; 2022 ел, 29 июль, 731 нче; 2022 ел, 6 октябрь, 1075 нче; 2023 ел, 17 апрель, 481 нче; 2023 ел, 25 октябрь, 1351 нче; 2024 ел, 20 сентябрь, 815 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәдә:

8.2 пунктта:

икенче абзацта «92» саннарын «91» саннарына алмаштырырга, «15» саннарын «12» саннарына алмаштырырга;

унбишенче абзацта «җиде» сүзен «алты» сүзенә алмаштырырга;

уналтынчы абзацта «дүрт» сүзен «өч» сүзенә алмаштырырга;

унҗиденче абзацта «биш премия» сүзләрен «дүрт премия» сүзләренә алмаштырырга;

унсигезенче абзацта «алты» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Безнең заман казанышы» кубогы бирелгән командага диплом һәм 200,0 мең сум күләмендә акчалата премия бирүне раслый торган сертификат тапшырыла.»;

әлеге карар белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан С.Р.Андреевны, А.В.Мищихинны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Әхмәтова Регина Рәфикъ кызын | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләренең кадрлар потенциалын үстерү бүлеге башлыгын, оештыру комитеты секретарен |
| Прытков Евгений Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының иҗтимагый тәртип саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеген оештыру идарәсе башлыгын (килешү буенча) |
| Рюхов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын; |

Ринат Наил улы Садыйковның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин